КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 октябрь г.Казань № 956

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче, 2020 ел, 24 июль, 621 нче

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="16">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td><td colspan="3">Программаны финанслауның гомуми күләме – 21 614 471,38 мең сум[*] тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 12 575 042,1 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 039 429,28 мең сум:<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Җәлеп итергә планлаштырылган федераль бюджет акчалары</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>957 036,6</td><td>668 907,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>771 639,0</td><td>631 712,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>742 042,5</td><td>683 366,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>609 879,1</td><td>721 262,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>575 168,1</td><td>755 325,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 124 229,6</td><td>766 880,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>3 239 653,7</td><td>784 640,5</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 008 597,1</td><td>794 878,9</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 028 769,5</td><td>809 122,4</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>839 342,3[*]</td><td>807 777,6[*]</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>839 342,3[*]</td><td>807 777,6[*]</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>839 342,3[*]</td><td>807 777,6[*]</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>12 575 042,1[*]</td><td>9 039 429,28[*]</td></tr>
<tr><td colspan="3">[*]2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;</td></tr>
</table>

Программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «I. Программаны тормышка ашыру сферасының характеристикасы, әлеге өлкәдә төп проблемалар

Әлеге Программа Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законы нигезендә эшләнгән, алар халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү буенча дәүләт сәясәтенең хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләрен билгели.

Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт сәясәте түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

хезмәт ресурсларын үстерү, аларның мобильлеген арттыру, милли хезмәт базарын яклау;

милләтенә, җенесенә, яшенә, социаль хәленә, сәяси инануларына һәм дингә карата булган мөнәсәбәтләренә карамастан, ирекле хезмәткә һәм эш белән тәэмин ителүне ирекле сайлау хокукын тормышка ашыруга барлык гражданнарга тигез мөмкинлекләр тәэмин итү;

кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар тудыру;

гражданнарның закон кысаларында гамәлгә ашырыла торган хезмәт һәм эшмәкәрлек инициативаларына булышлык күрсәтү, аларның җитештерү, иҗади хезмәткә сәләтләрен үстерүгә ярдәм итү;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүче чараларны гамәлгә ашыру;

массакүләм эшсезлекне кисәтү һәм озак (бер елдан артык) эшсезлекне кыскарту;

барыннан да элек, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар өчен гамәлдәге эш урыннарын саклаучы һәм яңаларын булдыручы эш бирүчеләрне бүләкләү;

хезмәт базарында катнашучыларның тырышлыгын берләштерү һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашырганда аларның гамәлләренең ярашуы.

Программа алдагы елларда халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү буенча республика программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен, шулай ук республика территориясендә 2009 елдан гамәлгә ашырыла торган төбәк программалары кысаларында хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны исәпкә ала.

Халыкны эш белән тәэмин итү программаларын гамәлгә ашыру барышында күрелгән чаралар Татарстан Республикасында халыкның мәшгульлеге белән бәйле ситуациягә уңай йогынты ясады.

2020 ел башына Татарстан Республикасы халкының гомуми саны 3,9 млн. кеше тәшкил иткән, шул исәптән 2,2 млн. эшкә яраклы яшьтә, һәр дүртенче кеше өлкән буынга карый. Республика өчен эшкә яраклы яшьтәге гражданнар саны кимегәндә, эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәе гражданнар саны артуның гомумдөнья тенденциясе хас. Моннан тыш, процент пункты акрынлап кимү белән эшкә яраклы яшьтән яшьрәк гражданнар саны арту (елына 1 – 2 процент) борчу тудыра.

Республика үсешенең төрле яктан характеристикасын, проблемаларын һәм юнәлешләрен үз эченә алган Глобаль документ – 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе.

Җитештерүне модернизацияләү, яңа технологияләргә күчү, яңа югары җитештерүчәнлекле эш урыннары булдыру «сыйфатлы» эшче көчләр, югары квалификацияле хезмәткәрләр таләп итә.

Төбәк икътисадый, социаль һәм сәяси параметрлар буенча арттыру өчен кеше ресурсын үстерү һәм аны куллану нәтиҗәлелегә кебек аспект зур әһәмияткә ия.

Төбәкнең икътисадый уңышларын фаразлау сәясәтен тормышка ашыру, шул исәптән эшче көчләргә ихтыяҗны фаразлау һәм төбәк икътисадының кадрлар әзерләүгә ихтыяҗы аша ирешелә.

Соңгы елларда хезмәт базарында уңай тенденцияләр сизелә, алар эшсезлек дәрәҗәсе түбән һәм эшче көчләргә даими ихтыяҗ булу белән характерлана.

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча, 2019 елда эшче көчләр саны 2 036,1 мең кеше (2018 елда – 2 037,2 мең кеше), яисә республика халкының 52 проценты (алар арасында республика икътисадында мәшгульләр саны 1 969,7 мең кеше (2018 елда – 1 969,5 мең кеше, МОТ методологиясе буенча исәпләнгән эшсезләр саны– 66,4 мең кеше (2018 елда – 67,7 мең кеше) тәшкил итте.

МОТ методологиясе буенча исәпләнгән гомуми эшсезлек дәрәҗәсе 2019 елда уртача 3,3 процент тәшкил иткән. 2011 елдан 2019 елга кадәр республикада гомуми һәм теркәлгән эшсезлекнең кимүе тенденциясе сакланып калган. МОТ методологиясе буенча исәпләнгән эшсезләр саны 2011 елдан (95,5 мең кеше) 44 процентка кимегән. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында социаль хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчъяклы комиссиясе янәшәсендә халыкның тормыш дәрәҗәсе, керемнәре, хезмәткә түләү буенча Координация советының чираттагы утырышы узды.

2020 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы вәзгыять пандемия һәм кайбер чикләү чаралары кабул итүгә бәйле рәвештә бераз катлауланды.

2020 елның апреленнән республиканың халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенә гражданнар мөрәҗәгате шактый арткан.

Ел башыннан алып теркәлгән эшсезләр саны 10 903 кешедән 79 254 кешегә кадәр арткан (2020 елның 27 августына булган мәгълүматларга караганда). Җайга салына торган эшсезлек дәрәҗәсе 3,9 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять икътисадый активлыкны нормальләштерү белән тотрыклана бара.

Татарстан Республикасы буенча эшсезлек үсеше темплары кимүгә таба бара. Әгәр иң кызу чорда (апрельнең соңгы декадасында) эшсезләр статусын атна саен 15 меңгә якын кеше алса, соңгы17 – 23 августлар атнасында 2 174 кеше эшсез дип танылган.

2020 елның 27 нче августына эш бирүчеләр тарафыннан игълан ителгән вакансияләр саны 45,9 мең берәмлек тәшкил иткән. Эш бирүчеләр тарафыннан игълан ителгән хезмәткәрләргә ихтыяҗ 2020 елның мартыннан 2020 елның маена кадәр кимегән, 2020 елның июнь – август айларында арта башлаган.

Хезмәт базарында киеренкелек коэффициенты вакансиягә 1,7 кеше тәшкил итә.

2020 елның 7 аенда 19 274 кеше эшкә урнаштырылган, шуларның 14 379ы – эш белән тәэмин ителмәгән гражданнар.

Соңгы елларда хезмәт базарының уңай үзгәрешләренә хезмәткәрләргә даими ихтыяҗ булу керә. Хезмәт миграциясе икътисадның мөһим элементларыннан берсе, хезмәт базарының нәтиҗәле коралы булып тора. Миграция процесслары эш бирүчеләр тарафыннан аерым эш төрләрен башкаруга яки кыска вакыт аралыгында эшләүгә гариза бирелгән вакантлы эш урыннары тутыруның төп чыганакларыннан

берсе булып кала бирә. Якын һәм ерак чит ил гражданнары өчен каралган эш урыннары республика халкы тарафыннан тутырылмый.

Россия Федерациясе хөкүмәте ел саен чит ил хезмәткәрләрен, шул исәптән өстенлекле һөнәри-квалификация төркемнәре буенча, сәяси, икътисадый, социаль һәм демографик ситуацияне исәпкә алып, җәлеп итүгә ихтыяҗны билгели, шулай ук чит ил эшче көчләрен куллануның нәтиҗәлелеген бәяли. 2020 елга чит ил хезмәткәрләренә ихтыяҗ – эшкә 1,7 мең рөхсәт, 2021 елга – эшкә 2,1 мең рөхсәт (2019 елда – эшкә 3,7 мең рөхсәт) күләмендә билгеләнгән.

Эшче көчләргә ихтыяҗ, күпчелек очракта югары квалификацияле эшче көчләргә ихтыяҗ, эшче көчнең булган тәкъдимен тормышка ашыру өчен җитәрлек түгел һәм аны канәгатьләндерү элеккечә үк эшче көчләргә ихтыяҗның һәм тәкъдимнәрнең структур туры килмәве белән тоткарлана.

Һөнәри-квалификация, шулай ук эшче көчләргә ихтыяҗның һәм тәкъдимнәрнең территориаль туры килмәве сәбәпле, республиканың аерым оешмалары эшче көчләргә, бигрәк тә аерым һөнәрләр буенча югары квалификацияле кадрларда һәм квалификациясез хезмәткәрләрдә кытлык кичерүләрен дәвам итә. Бу хезмәт базарын җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру чараларын планлаштыру кирәклеген, хезмәт ресурсларының территориаль мобильлеген арттыру һәм чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү чараларын да кертеп, билгели.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, гражданнарның түбән хезмәт мобильлегенең төп сәбәпләре булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясенең башка субъектларында гаилә әгъзалары белән эшкә урнашу һәм урнаштыру мөмкинлекләре турында җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүмат бирмәү;

белгечләрне кабул итү өчен кирәкле инфраструктура булмау (торак, балалар бакчалары, медицина учреждениеләре);

эре инвестицион проектларны планлаштырганда һәм гамәлгә ашырганда эшләү өчен белгечләр туплау механизмнарының үсмәве.

Хәзерге хезмәт базарында тагын бер актуаль проблема булып гражданнарны эшкә урнаштыру проблемасы кала, алар төрле сәбәпләр аркасында (социаль, физик һәм башка) көндәшлеккә иң аз сәләтле булып торалар. Болар – кече яшьтәге балалары булган хатын-кызлар, күп балалы ата-аналар, инвалид балаларның ата-аналары, сәламәтлекләре буенча эшкә яраклылык чикләре булган гражданнар, пенсия алды һәм пенсия яшендәге гражданнар, яшьләрнең аерым категорияләре (һөнәри белеме булмаганнар яки эш тәҗрибәләре булмаган һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар) һәм башка категория гражданнар (хәрби хезмәттән азат ителгән, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар).

Татарстанстат үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, республиканың икътисади актив халкының саны 2009 елдан башлап арта. Эшче көчләр структурасында эшсезләрнең гомуми саны кимегәндә, икътисадта мәшгульләр саны арту тенденциясе күзәтелә.

Пенсия законнарының 2019 елдан башлап пенсия яшен арттыру өлешендә параметрлары үзгәрү эшкә яраклы яшьтәге эшкә сәләтле халык санын арттыруга китерә. 2019 елдан 2022 елга кадәр Татарстан Республикасының эшкә яраклы яшьтәге эшкә сәләтле халык саны уңай динамикага ия булыр дип фаразлана, чөнки эшкә яраклы яшькә керүче затлар саны пенсия яшенә җиткән гражданнар саныннан күбрәк булачак.

Татарстан Республикасында икътисадта мәшгульләр саны сизелерлек кимиячәге фаразланмый. Татарстан Россия Федерациясенең миграцион яктан җәлеп итә торган төбәге булып тора. 2019 ел ахырына хезмәт эшчәнлеген башкаручы чит ил гражданнары саны 52 284 кеше тәшкил иткән, шуларның 5 777се вакытлыча яшәүгә рөхсәт алган һәм 7 044 кеше яшәүгә рөхсәт алган. 2020 елның 1 апреленә хезмәт эшчәнлеген башкаручы чит ил гражданнары саны 1090 кешегә арткан һәм 53 374 кеше тәшкил иткән.

Чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны эшкә урнаштыру белән бәйле процессларны мониторинглау икътисад һәм хезмәт базары үсеше перспективаларын исәпкә алып, чит ил эшче көчләренә ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен нәтиҗәле механизмнар булдыру кирәклеген ачыклады.

Икътисади вәзгыятьтә килеп туган уңай тенденцияләрне саклап калу һәм эшче көчләргә ихтыяҗ арту белән бергә, МОТ методологиясе буенча исәпләп чыгарылган эшсез гражданнар саны кимиячәк. Эшсезлекнең кимүенә демографик структураның үзгәрүе дә ярдәм итәчәк: эшсезлек куркынычы аеруча зур булган яшьләр саны шактый кимиячәк.

Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты арту белән эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче эшсез гражданнар саны артачак. 2025 ел ахырына теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе республиканың икътисади актив халкы саныннан 0,6% тан артмаячак.

Хезмәтне саклау хезмәт эшчәнлеге барышында гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклауның мөһим шарты булып тора. Хезмәтне саклау белән дәүләт идарәсе системасы хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга, хезмәт процессында кешенең сәламәтлеген һәм эшкә сәләтен саклау буенча хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитар-гигиена, дәвалау-профилактика һәм башка чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасында хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тиешле закон һәм башка норматив актлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Хезмәтне саклау белән дәүләт идарәсе системасын үстерү республика җитәкчелегенең якындагы елларга иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора, аны хәл итү социаль-икътисадый сәясәт үткәрүдә барлык структураларның һәм дәүләт идарәсенең эшчәнлеген координацияләү аша мөмкин.

Республикада Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында, республиканың муниципаль берәмлекләрендә хезмәтне саклау хезмәтләрен булдыру мәсьәләсе буенча максатчан эш алып барыла. Тармак дәрәҗәсендә барлык министрлыкларда да хезмәтне саклау хезмәтләре (бүлекләр, секторлар, хезмәтне саклау төркемнәре) булдырылды, хезмәтне саклау буенча азат ителгән белгечләрне җәлеп итү, министрлык һәм ведомство аппаратларының башка хезмәткәрләренә вазыйфалар йөкләү тәҗрибәсе кулланыла. Республиканың 10 муниципаль берәмлегендә дә хезмәтне саклау мәсьәләләре белән функциональ шөгыльләнәләр.

Анализ күрсәткәнчә, тикшерүләр вакытында хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча ачыкланган хокук бозуларның төп өлешен хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне укыту һәм инструкцияләү белән бәйле хокук бозулар тәшкил итә.

Эш бирүчеләрнең һәм оешма хезмәткәрләренең хезмәтне саклау өлкәсендә белемнәренең җитмәве, үз хезмәткәрләренең иминлеге өчен социаль җаваплылыкның түбән дәрәҗәсе белән бер үк вакытта, үлем-китем очракларының гына түгел, авыр нәтиҗәләргә китергән травмаларның да шактый үсүенә китерә. Бу бурычны хәл итү максатларында хезмәтне саклау өлкәсендә укыту һәм һөнәри әзерлек оештырырга кирәк, алар, үз чиратында, җитештерүдәге имгәнүләрне профилактикалауга юнәлдерелгән.

Куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру, травматизмны булдырмау оештырылган мәгълүмат белән тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалауга бәйле, ул кешеләрнең тормыш позициясенә тәэсир итүче эмоциональ халәт, аларның производствода тормыш һәм сәламәтлекне саклауга бәйле төрле ситуацияләрдә үз-үзләрен тотышы формалаштыру максатларында фән һәм техниканың соңгы казанышлары турында мәгълүматны, идеяләрне, мәгълүматларны таратуга юнәлдерелгән.

Заманча хезмәт базары эшче һәм инженер һөнәрләре буенча кадрларга кытлык кичерә, аларның абруе шактый югалды, кадрларның дәвамчанлыгы юк. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык, машина төзелеше, авыл хуҗалыгы, транспорт, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәләрендә эшче кадрлар җитми.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисадының кадрлар әзерләүгә һәм югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтелгән әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы 2021 – 2027 елларга квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә ихтыяҗ фаразын формалаштырды. Кергән мәгълүматларны анализлау күрсәткәнчә, 2021 – 2027 елларга эшче кадрлар һәм урта һөнәри белемле белгечләр әзерләүгә ихтыяҗ кадрлар әзерләүгә гомуми ихтыяҗның 72 процентын тәшкил итә.

Эш белән тәэмин итү хезмәте органнары мәгълүматларына караганда, эш бирүчеләр игълан иткән вакансияләр составында 67 проценттан артыгы эшче һөнәрләренә туры килә.

Эшче һөнәрләрнең җәлеп итүчәнлеген көчәйтү һәм гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның һөнәри тибын коррекцияләү буенча һөнәри юнәлеш бирү эше алып бару зарур.

Икътисадның эшче һәм инженерларга ихтыяҗын тәэмин итү проблемасы бик күп төрле. Һөнәри белем бирү системасының формалашкан хезмәт базарыннан тыш, кеше аңындагы үзгәрешләрнең мөһим аспекты бар. Эшче һәм техник белгечлекләрне пропагандалау булмау яшьләрнең алар турында хәбәрдар булмавына һәм әлеге һөнәрләрнең популярлыгын киметүгә китерә.

Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыруда уңай нәтиҗәләргә ирешүнең нәтиҗәле ысулы булып бюджетның чикләнгән ресурсларын оптимальләштерергә, хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырырга, куелган бурычларны хәл итү өчен аларның көчләрен берләштерергә мөмкинлек бирә торган программа-максатчан планлаштыру методын куллану тора. Программа тарафыннан куелган бурычларны үтәүгә җитештерү күләмен киметү, инфляция үсеше, социаль

киеренкелекне арттыру, халыкның тормыш дәрәҗәсен киметү, эштән күпләп азат итү һәм, нәтиҗәдә, хезмәт базарындагы вәзгыятьнең начараюы, эшсезлек үсеше комачауларга мөмкин. Әлеге куркынычларны җиңеп чыгу хезмәт базарына һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга өстәмә бюджет акчаларын бүлеп бирү юлы белән була.

Хәзерге хезмәт базарының төп проблемалары булып түбәндәгеләр кала бирә:

хезмәт базарында эшче көчләргә ихтыяҗның һәм тәкъдимнәрнең туры килмәве;

гражданнарның түбән хезмәт мобильлеге;

төрле сәбәпләр аркасында (социаль, физик һәм башка) эшкә урнашуда кыенлыклар кичерүче һәм иң аз конкуренциягә сәләтле булган гражданнарны эшкә урнаштыру.

Республика производстволарында куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү өчен түбәндәге төп юнәлешләрне билгеләргә кирәк, алар киләчәктә производствода имгәнүләрне, һөнәри авыруларны киметүдә һәм эш урыннарында хезмәт шартларын яхшыртуда уңай роль уйнарга тиеш:

республика, тармак һәм муниципаль дәрәҗәләрдә хезмәтне саклауны тәэмин итүнең нәтиҗәле инфраструктурасын булдыру;

республика оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт куркынычсызлыгы дәрәҗәсен гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп күтәрү.

Икътисадның эшче һәм инженерларга ихтыяҗын тәэмин итү проблемасын хәл итүгә эшче һәм инженерларга ихтыяҗ зур булачак:

халыкның барлык катламнарына хезмәт базарындагы реаль хәл һәм эшче һәм инженер һөнәрләренең ихтыяҗы турында мәгълүмат бирү эшен активлаштыру;

яшьләр арасында профориентацион чаралар үткәрү.»;

Программаның III бүлегендә:

икенче – дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 21 614 471,38 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге акча хисабына:

федераль бюджет – 12 575 042,1 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты – 9 039 429,28 мең сум.»;

Программага 1 нче кушымтаның «Бер ел эчендә уртача эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча (алга таба – МОТ), процент» юлында 12 графада «3,5» саннарын «3,8» саннарына алмаштырырга;

Программага 2 нче кушымтаның 9 графасында:

«Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт миграциясен җайга салу чараларын гамәлгә ашыру. Эшкә урнаштырганда яшь яшьтәге инвалидларны озату» юлында «3 344 596,5», «774 636,1», «2 569 960,4» саннарын «4 009 664,2», «770 010,5», «3 239 653,7» саннарына алмаштырырга;

«Программа буенча барлыгы , шул исәптән:» юлында «3 359 226,5» саннарын «4 024 294,2» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлында «789 266,1» саннарын «784 640,5» саннарына алмаштырырга;

«федераль бюджет (җәлеп итүгә планлаштырыла торган акчалар)» юлында «2 569 960,4» саннарын «3 239 653,7» саннарына алмаштырырга;

«Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт миграциясен җайга салу чараларын гамәлгә ашыру. Эшкә урнаштырганда яшь инвалидларны озата бару» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программасын финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="16">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программасын финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программасын финанслауның гомуми күләме 21 438 176,38 мең сум тәшкил итә*, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырылган федераль бюджет акчалары – 12 575 042,1 мең сум*, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 8 863 134,28 мең сум*, шулардан, яшь инвалидларны да кертеп, инвалидларны эш белән тәэмин итүгә һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык итүгә – 308,7 млн сум:<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Гомуми акча күләме</td><td>Җәлеп итергә планлаштырылган федераль бюджет акчалары</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>1 611 314,39</td><td>957 036,6</td><td>654 277,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 388 721,01</td><td>771 639,0</td><td>617 082,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 410 779,48</td><td>742 042,5</td><td>668 736,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 315 776,8</td><td>609 879,1</td><td>705 897,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>1 315 863,1</td><td>575 168,1</td><td>740 695,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 876 479,8</td><td>1 124 229,6</td><td>752 250,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>4 009 664,2</td><td>3 239 653,7</td><td>770 010,5</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 788 846,0</td><td>1 008 597,1</td><td>780 248,9</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 823 261,9</td><td>1 028 769,5</td><td>794 492,4</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 632 489,9*</td><td>839 342,3*</td><td>793 147,6*</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1 632 489,9*</td><td>839 342,3*</td><td>793 147,6*</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>1 632 489,9*</td><td>839 342,3*</td><td>793 147,6*</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>21 438 176,38*</td><td>12 575 042,1*</td><td>8 863 134,28*</td></tr>
<tr><td colspan="4">* 2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;</td></tr>
</table>

«Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарның күченүсез эшсез гражданнарга ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтен алу һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җиргә күчүдә ярдәм итү халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләрен эшкә урнаштыру өчен, әлеге дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән кешеләрнең 100 проценты;»;

ярдәмче программаның II бүлегендә:

унтугызынчы абзацта «, шулай ук гражданнарны җитештерү, территориальара һәм тармакара эшче көчләрне бүлү һәм чит ил хезмәткәрләрен куллану процессына җәлеп итү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

җитмешенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарның күченүсез эшсез гражданнарга ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтен алу һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җиргә күчүдә ярдәм итү халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләрен эшкә урнаштыру өчен, әлеге дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән кешеләрнең 100 проценты;»;

ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «20 773 108,68» саннарын «21 438 176,38» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «11 905 348,8» саннарын» 12 575 042,1 « саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «8 867 759,88» саннарын «8 863 134,28» саннарына алмаштырырга;

ярдәмче программага 1 нче кушымтаның 10 пунктында «кимендә 54» сүзләрен «кимендә 30» сүзләренә алмаштырырга;

ярдәмче программаның 2 нче кушымтасындагы «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт миграциясен җайга салу чараларын тормышка ашыру. Эшкә урнаштырганда яшь инвалидларны озата бару» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасында:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.4. Социаль-икътисадый һәм хокукый хәлне, матди хәл дәрәҗәсен һәм хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының, хәзерге шартларда хәрби хезмәт ветераннарының хокукый якланышын тикшерүне оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы | 2019 – 2025 еллар | сораштыры лучылар саны, кеше, кимендә | 300 | 400 | 450 | 450 | 450 | 450 | 450 | ТР бюджеты | 495,0 | 495,0 | 495,0 | 495,0 | 495,0 | 495,0 | 495,0»; |

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.9. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыруга административ чыгымнар | ТР Хезмәт министрлыгы, ХСЯ ДУ | 2019–2025 еллар | халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә ХСЯ ДУ вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдалану нормативларын үтәү, процент | 100 | 97 | 97 | 97 | 97 | 97 | 97 | ТР бюджеты | 382 225,7 | 408 590,3 | 407 829,5 | 421 791,2 | 420 697,1 | 420 697,1 | 420 697,1»; |

2.2 пунктының 14 графасында «49 988,4» саннарын «43 152,9» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.2.5 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.2.5. Студентларны, югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы, ХСЯ ДУ | 2020 ел | халык саны эш белән тәэмин ителгән өч ай дәвамында студентлар, белем алучы югары белем программалары буенча, кеше | | 250 | | | | | | ТР бюджеты | | 6 835,5»; | | | | | |

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.3. Эшсез гражданнарга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен башка җиргә күчүдә ярдәм итүне оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы, ХСЯ ДУ | 2019 ел | хисап чорында теркәлгән эшсезләр санына карата дәүләт хезмәте алган гражданнар санының нисбәте, процент | кимендә 0,33 | | | | | | | ТР бюджеты | 850,0 | 900,0 | 950,0 | 950,0 | 950,0 | 950,0 | 950,0»; |
| | | 2020–2025 еллар | эшсез гражданнарга күченүдә һәм күчеп килгән эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | буенча эшкә урнашуда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте алган гражданнар өлеше, әлеге дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр арасыннан, процент. | | | | | | | | | | | | | | | |

4.1 пунктының 14 графасында «143 437,9» саннарын «133 219,9» саннарына алмаштырырга;

4.1.2 пунктының 6 графасында «60» саннарын «42» саннарына алмаштырырга;

4.1.3 пунктының 6 графасында «10» саннарын «4» саннарына алмаштырырга;

4.1.4 пунктының 6 графасында «10» саннарын «4» саннарына алмаштырырга;

4.1.5 пунктының 6 графасында «12» саннарын «5» саннарына алмаштырырга;

5.1 пунктының 14 графында «2 179 394,5» саннарын «2 895 587,8» саннарына алмаштырырга;

5.2 пунктның 14 графасында «58 000,0» саннарын «31 500,0» саннарына алмаштырырга;

5.3 пунктта:

6 графада «2» санын «1» санына алмаштырырга;

14 графада «64 100,0» саннарын «44 100,0» саннарына алмаштырырга;

«Ярдәмче программа буенча барлыгы» юлының 14 графасында «1 779 863,1» саннарын «4 009 664,2» саннарын алмаштырырга;

«Җәлеп итүгә планлаштырыла торган федераль бюджет чаралары» юлының 14 графасында «112 672,0» саннарын «3239 653,7» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты акчалары» юлының 14 графасында «767 191,1» саннарын «770 010,5» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин